**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**№ 9** **штб Урыссу** **17. 06. 2020 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2018 елның 5 октябрендәге «Шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 23 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Ютазы районы Прокурорының 2009 елның 20 декабрендәге 02-08-01 санлы протестын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советы к а р а р и т т е:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмәләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 6 маддәсенең 1 пунктындагы 1.1 пунктчасындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм (яки) бүтән мәгълүмати системаларда һәм мәгълүмати стендларда басылып чыга.»

2. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәмhttp://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башлыгы урынбасары Р.М. Гарипов